

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

# БАЛАҢ БӘЛАГӘ ЮЛЫКМАСЫН, ДИСӘҢ...

**Түбән Камада әнисе арбада йоклатып калдырган биш айлык сабый үлгән. Юындырганда әнисенең кулы шуып китеп, башы белән плитәгә килеп төшкән өч атналык сабыйның да гомере өзелгән. Чаллыда, фатирдагы бөтен ишек-тәрәзәләрне бикләп, тиз генә кибеткә чыгып керергә уйлаган әни кеше исә подъезд төбендә улының аңсыз гәүдәсенә тап була.**


pixabay.com

Белгечләр балалар белән килеп чыккан башка фаҗигаләрдә ата-ананы гаепли. Ул гына да түгел, бер ел эчендә республикада әти-әниләрнең игътибарсызлыгы аркасында үлгән сабыйлар саны ике мәртәбә (!) арткан. Сүз өч яшькә кадәрге балалар турында бара. Чагыштыру өчен: 2011 елда әти-әнинең ваемсызлыгы аркасында 11 баланың гомере өзелгән булса, узган ел андый фаҗигале очраклар саны 21гә җиткән. «Иң аянычлысы шул: мондый очракларның артуына ниндидер бәхетсезлек очрагы да, юл фаҗигасе дә сәбәпче түгел. Мисал өчен, әни кеше бер яше дә тулмаган кечкенә сабыйны үз янына яткырган килеш йокыга китә дә иртүк уянганда аның җансыз гәүдәсенә тап була. Мондый аянычлы очраклар бихисап», – ди хокук сакчылары.

Тәҗрибәле табиб-травматолог Венер Мәсхүтов төп гаепне заманча гаджетларда күрә. «Замана ата-аналарының күбесе үзләре дә балалыктан чыгып бетмәгән. Араларында баласына игътибарлырак буласы урынга телефон, планшеттан күзен ала алмыйча утырганнары шактый. Ә бит бала мизгел эчендә җәрәхәт ала. Көчемнән килсә, яңа өйләнешкән парларга машина йөртү таныклыгы алыр алдыннан тапшырган имтихан кебек сынау уздырыр идем!» – ди белгеч.

Табиб сүзләренә караганда, соңгы елларда шул ук замана уенчыклары аркасында балалар имгәнүләргә ныграк бирешә башлаган.

– Урамда туп тибәсе урынга хәзерге балалар гаджетларга текәлеп утыруын белә. Нәтиҗәдә күбесенең мускул тукымалары зәгыйфьләнә. Шуңа күрә алар тигез җирдә дә җитди җәрәхәт ала. Мисал өчен, элегрәк җиргә егылган баланың аягында күгәргән урын гына пәйда була иде. Хәзер исә күбесенең бер егылуда ук аягы имгәнергә мөмкин, – ди Венер Мәсхүтов.

Балалар арасында фаҗигале очракларны булдырмас өчен, әти-әниләргә түбәндәге кагыйдәләрне истә тотарга куша ул.

### Пешү

– Ашарга әзерләгәндә кәстрүл яки табаны плитәнең арткы конфоркасына куегыз. Тоткычлы табаларның тоткычын эчке якка каратып куйсаң хәерле. Өстәл өстенә кайнар ризык куйганда аның астында озын сөлге, ашъяулыклар да булмаска тиеш.
– Тиз янып китә торган сыеклык, шырпы, шәм, петарда кебек әйберләр дә балалар буе җитмәслек урында торырга тиеш. Табигатьтә ял иткәндә баланы учак янына якын китерергә ярамый.
– Баланы юындырыр алдыннан иң элек суның җылылыгын тикшерегез.

### Биеклектән егылып төшү

– Москит челтәренә ышанмагыз. Ул, киресенчә, фаҗигагә этәрә генә. Күп очракта балалар нәкъ менә шушы сетка белән бергә очып төшә.
– Тәрәзә янында берниндиҗиһаз тормасын, бала менәрлек булмасын.
– Тәрәзәне өстән ачарга тырышыгыз.
– Тәрәзәне берничә сантиметр гына ачарлык итеп чикләгеч куегыз.
– Тәрәзәгә рәшәткәләр куйсагыз, җаныгыз тыныч булыр.
– Балага түбә, гараж, төзелеш барган урыннарда йөрергә рөхсәт итмәгез.

### Суга бату

– Балалар аз сулы урында да ким дигәндә 2 минут эчендә батарга мөмкин. Шуңа күрә йорттагы кое, ванна, су мичкәсе, сулы чиләкләр капланган булырга тиеш.
– Кечкенә чактан ук йөзәргә өйрәтегез. Йөзә белгән балага да коткару жилеты киертсәң хәерле. Су янында баланы игътибарсыз калдырмагыз.

### Сулыш кысылу

– Яше тулмаган баланы үз янызгызда йоклатмагыз.
– Балаларга төшле ризыклар, көнбагыш бирергә ярамый.
– Ашаганда баланы көлдерү, уйнату – зур хата.

### Агулану

– Өйдәге дарулар бала кулы җитми торган урында сакланырга тиеш. Авырган чакта балага даруны табиб кушуы буенча һәм инструкциядә язылганнарга таянып кына эчертегез.
– Агулы матдәләрне, агарткыч, кислота кебек кирәк-яракны ныклап ябыла торган савытта, балалардан яшерен урында саклагыз.
– Гаилә белән урманга барганда да баланы игътибарсыз калдырмагыз.

### Ток сугу

– Электр розеткаларын махсус саклагыч капкачлар астына яшерегез.
– Балалар ут чыбыклары белән дә уйнарлык булмасын.

### Юлда җәрәхәтләнү

– Балага кечкенәдән үк юлда, машинада, җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен өйрәтегез.
– Балаларга юл кырыенда, аеруча туп белән уйнарга ярамаганлыгын да төшендерегез.
– Машинада барганда баланы махсус утыргычка утыртып, куркынычсызлык каешын эләктерергә онытмагыз.

### Таеп егылу

– Чанада, тимераякта шуганда бер-береңә бәрелеп җәрәхәтләнмәс өчен, кеше күп җыелган җирдә шумаска кирәклеген аңлатыгыз.
– Балаларыгыз кулларын кесәдән чыгарып йөрсен, егылган очракта куллар тигезлекне саклап калырга әзер булырга тиеш.
– Балаларның кышкы салкында тимер җиһазларны ялап карый торган гадәте бар. Андый чакта балага металлга каты итеп өрергә кушыгыз. Җылы һава тимерне җылытачак. Алай да ярдәме тимәсә, телгә җылы су сибеп, металлны җылытуны дәвам итәргә кирәк. Озакламый ябышкан тел дә ычкыначак.

## Хуш, имезлек!

Тәҗрибәле балалар табибы Раушания Хафизова фикеренчә, баланы имезлектән мөмкин кадәр иртәрәк – 7–8 айлык чагында ук аера башласаң хәерле. «Тик бер шарт бар: бала аның белән хушлашуга рухи яктан әзер булырга тиеш. Юк икән, бу эшне бер яшькә кадәр кичектереп торырга кирәк. Бер яше тулмаган бала белән яше тулган баланы имезлектән аеру ысуллары шактый аерыла», – ди белгеч.

### 1 яше тулмаган нарасыйны имезлектән аеру өчен:

Имезлек күзгә мөмкин кадәр сирәгрәк ташланса хәерле. Сабый аны сорап елый башласа, аның игътибарын тәм-том, кызыклы уенчык ише әйберләр белән читкә юнәлтергә тырышыгыз. Алай да ярдәме тимәсә, баланы кулыгызга алып тынычландырыгыз. Бераз сабыр булсагыз, иртәме-соңмы имезлек бала өчен әһәмиятле әйбер булудан туктаячак.

Имезлектән аерырга ике-өч атна кала, баланың йокыга китү рәвешен үзгәртергә тырышыгыз. Әкият сөйләү, җыр көйләү, баланың аркасыннан, корсагыннан сыпырып ятуларны көн дә гадәткә кертегез. Сабый имезлекне искә төшерерлек булмасын.

Сабыйга җиде-сигез ай булуга, аны чынаяктан чәй эчәргә өйрәтегез. Зурларча чәй эчәргә өйрәнгән бала имезлекне тиз ташлый.

### 1 яше тулган баланы имезлектән аеру өчен:

Бу чорда бала әкиятләргә ышана башлый. Шуңа күрә «урамга чыккан чакта имезлекне эт, мәче, аю, бүре һ.б. урлаган» ише уйдырмаларның да файдасы тиеп куюы бар.

Имезлекне кунакка барган җирдән «югалтып» кайтсагыз да була. Кайбер баланың моңа исе дә китми. Әгәр сабый өзгәләнеп имезлек сорап елый башласа, аны кире кайтару хәерле. Димәк, әле вакыты җитмәгән.

Имезлек өзелгән, ватылган очракта, яңасы артыннан даруханәгә йөгерергә ашыкмагыз. Форсаттан файдаланып, балага: «Күрдеңме, имезлегебез ватылды. Синең кебек зур малайга (кызга) хәзер мондый имезлек сатмыйлар инде», – дип аңлатсагыз да була.

АКШ белән Канадада шундый кызыклы йола бар. Анда Теш феясының туганы зур үскән баланың имезлеген алып китә дә йокыдан торышка аның урынына бер бик матур уенчык калдырган була.
Бу алымны да кулланып карарга мөмкин.

## САБЫЙЛАР АРАСЫНДА ФАҖИГАЛЕ ОЧРАКЛАРНЫ КИСӘТҮ ӨЧЕН НИ ЭШЛӘРГӘ?

**Физәлия ДӘҮЛӘТГӘРӘЕВА, шагыйрә:**
– Бала имин үссен өчен, әни кешегә аңардан көне-төне күз алмаска кирәк, әлбәттә. Тик бу мөмкинме соң? Безнең җәмгыятьтә хатын-кызга бала карау, пешерү, юу кебек тавык та чүпләп бетермәслек мең мәшәкать өстәлгән. Шуларны башкарыр өчен игътибарыңны әз генә читкә юнәлтсәң дә, бала белән бер-бер хәл булуы мөмкин. Ә бит ике, өч балалы гаиләләр дә бар. Аларга вакыт та, игътибар да күбрәк кирәк. Балалар бакчасы җитмәү дә үз ролен уйный. Яшь әниләр, яшәргә чара табар өчен, балаларын чит кешегә ташлап, эшкә чыгарга мәҗбүр. Профессиональ бала караучы ялларга күпчелек гаиләнең мөмкинлеге юк. Теләсә кемгә бала калдырып та төрле хәл килеп чыгуы бик мөмкин. Яшьләргә хәзер яшәү бигрәк тә авырлаша. Алар ипотека буенча муеннан бурычлы. Әтиләре эштән кайтып керми. Ике-өч эштә эшли, әмма акчасы барыбер җитми. Ә бит уйлап карасаң, балага әтисе дә, әнисе дә тигез тәрбия бирергә тиеш. Тормыш кыйбатлана, бала үстерү елдан-ел авырлаша бара. Яшәргә чара эзләп, балаларга игътибар да, вакыт та кими бара. Дәүләт яшь гаиләләргә фатир ягыннан, матди яктан ярдәм итсә, бераз булса да яшьләрнең тормышлары җиңеләер, балаларга да игътибар күбрәк эләгер иде.

**Чулпан ИЛДАРХАНОВА, социология фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Гаилә һәм демография үзәге җитәкчесе:**
– Элегрәк оныкларга әби-бабайлар да күз-колак була иде. Пенсия яше озайтылу аркасында, хәзер аларның да онык сөеп утырырга вакытлары юк. Бу – бик кызганыч күренеш, билгеле. Әмма әлеге мәсьәлә якын киләчәктә хәл ителергә охшап тора. Хөкүмәт тарафыннан кабул ителгән «Демография» илкүләм проекты иң беренче чиратта сабыйларның балачагын куркынычсыз, имин итүне күздә тота. Элегрәк, балалар бакчасында урыннар җитми, шул сәбәпле әниләр декрет ялында озаграк утырырга мәҗбүр, дип зарланган булсак, әлеге проект кысасында 2024 елга бу проблема тулысынча хәл ителәчәк. Балалар бакчаларындагы ясле төркемнәрендә һәр балага урын җитәчәк. Бу исә – бала көнен имин шартларда уздырачак, дигән сүз.



Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

# АШАГАН БЕЛМИ, ТУРАГАН БЕЛӘ: ТӘМЛЕ БУЛСЫН, АЗ БУЛМАСЫН

Саба районындагы Шыңар авылында яшәүче Гөлнар Мөбарәкова турында «тәмле телле, тәмле куллы» диләр. Үзе исә тыйнак кына итеп: «Аш-суга килгәндә, миңа әле уңганнар рәтенә керергә иртәрәк», – ди. Гөлнар ханым аш-су серләре, хуҗабикәләргә киңәшләре, рецептлар белән уртаклашты.

**:: «Тәмле куллы» дигәнне тортлар пешергәнгә күрә әйтәләрдер сезгә?**

– Әниемә рәхмәт: аның «фирменный» гөбәдиясе генә ни тора! Бәлешенә исә күпләр тиңләшә алмас. Гомумән, әти-әни ягыннан туган апаларыбыз да аш-суга бик оста, мин генә шундый димәс идем. Ризык әзерләгәндә: «Тәмле булсын, аз булмасын», – дигән кагыйдәм бар. Ягъни һәрбер әйберне арттырып салырга, кызганмаска тырышам.

**:: Алайса сез өйдәгеләрне гел татлы ризыклар белән генә куандырып торасыздыр инде?**

– Камыр белән маташырга, гаиләмне тәмле таба ашлары белән сөендерергә яратам, әлбәттә. Әмма аларга андый бәхет еш эләкми. Эштән кайткач, камыр белән мәшәкатьләнәсе килми шул. Әмма синең тәмле ризыкларыңны, суынганын да көтмичә, мактый-мактый сыпыртып баручыларны күргәч, үзеңне тыеп калу кыен. Гәүдәне дә матур формада саклыйсы килә ич әле: шуңа аш-су бәйрәмен атнага ике-өч ясап алабыз. Соңгы елларда камырны төчегә генә куям. Кетердәп кенә тора, ашказанына да авыр түгел, пицца, өчпочмак, бәлеш өчен бик яхшы.

**:: Ә тортларга заказларыгыз күпме соң?**

– «Сникерс» дигәне бигрәк тә дан казанды, аны бер тапкыр заказ бирүчеләр кабат ала. Унынчы мәртәбә шуны сорап мөрәҗәгать итүчеләр дә булды. Дөрес, ул – хәйран вакытны ала торган, чыгымлы хезмәт. Аны пешерү өчен 7–8 сәгать вакыт кирәк. Ашаганда гына тиз һәм җиңел тоела бит ул, аш-су тирәсендә кайнаган кеше генә бер сыйга күпме хезмәт киткәнен чамалый.



**:: Моннан тыш тагын нинди шөгыльләрегез бар?**

– Күңелемә иң якын шөгыль – шул тортлар пешерү. Никахка яисә башка төрле мәҗлесләргә килешле итеп яулык бәйләтәм. Ефәк тасмалардан чәчәкле кәрзиннәр үрәм. Гомумән, күзем төшкән, күңел тарткан һәр нәрсәне башкарып карарга тырышам. Төп һөнәрем – ир хатыны һәм күп балалы әни исемен йөртү!

**:: Аш-суга кулы ятмаган яшь кызларга нинди киңәш бирер идегез?**

– Беркем дә бөтен нәрсәне белеп тумый, яши-яши өйрәнәбез. Тәҗрибә дә шуннан килә. Интернетта нәрсәгә генә өйрәтмиләр бит хәзер! Пешермәс җиреңнән пешерерсең. Шартлары да бар: кибет киштәләре тулы ризык. Бары теләк, изге ният һәм тәвәккәллек кирәк.

## РЕЦЕПТЛАР

### «Сникерс» торты

1 тортка кирәк: Безе өчен: **5 йомырка, 1,5 стакан шикәр комы**. Бисквит камыры өчен: **9 йомырка, 1 стакан шикәр комы, камыр көпшәкләндергеч, каймак**. Крем өчен: **2,5 банка кайнаган куертылган сөт, 300 гр чамасы сыер мае, 400 гр арахис чикләвеге, шоколад**.

«Сникерс» тортының авырлыгы 2200–2500 кг чамасы чыга. Тортны әзерләгәндә иң мөһиме – безе. Аны озаграк тотсаң, көяргә мөмкин, азрак тотсаң, кибеп бетми. Әйбәт безе ясау өчен якынча 2–3 сәгать кирәк. Бисквит пешеп чыккач, тортны безе, крем сылап җыябыз, өстен фантазия ничек куша, шулай итеп бизибез.

### Дәмләмә

**1 тавык түшкәсе, 5–6 помидор, 6–7 суган, 1 сарымсак, уртача зурлыктагы ярты баш кәбестә, 7–8 кишер һәм бәрәңге, 3–4 дәфнә яфрагы (лавр), тәменчә тоз, борыч.**

Казанга (чуенга) һәркайсын катлам-катлам итеп тезәбез: иң төпкә 3–4 кисәккә бүлгәләп помидор, эрерәк кисәккә турап кәбестә, бүлгәләнгән тавык ите (алдан тоз сибеп, бераз тотарга да мөмкин), тоз-борыч, дәфнә яфраклары, сарымсак, ярым боҗралап туралган суганның бер өлешен, түгәрәкләп туралган кишер телемнәре, түгәрәкләп бәрәңге һәм калган суганны салып, шулай ук бераз тоз салып, капкачын каплап, иң сүрән утка куеп пешерәбез.

### Гармун-бәрәңге

**10–12 бәрәңге, 250–300 гр тирәсе казылык һәм сыр, 3 аш кашыгы майонез, 1 чәй кашыгы аджика.**

Мичне алдан 260 градуска кадәр җылытабыз. Бәрәңгене кабыгы белән яхшылап юып, аркылы кисемнәр ясап, тоз сибеп, майлы табага тезәбез, мичтә йомшарганчы пешерәбез. Ул арада майонез, аджика салып, соусын әзерлибез. Бәрәңге йомшаргач, кисемнәргә казылык телемнәре куябыз, өстенә соус агызабыз, сыр уябыз һәм яңадан мичкә озатабыз. Табынга кыяр-помидор кисәкләре белән бизәп чыгарырга.

### Бананлы десерт

Кирәк булачак: **1–2 банан, 250 гр каймак, 3–4 аш кашыгы шикәр комы**.

Бананнарны нечкә телемнәргә кисеп, тезеп чыгабыз. Каймак, шикәр комын миксер белән яхшылап болгатабыз, банан телемнәре өстенә агызабыз. Аннан соң какао порошогы сибеп, бизәп, табынга чыгарабыз.

### Ялкауларча хачапури

Камыр өчен: **3 стакан онга 1 йомырка, 1 чәй кашыгы тоз һәм сода, 400 гр кефир, 2 аш кашыгы үсемлек мае.** Йомшаграк итеп камыр басып, 40–50 минутка «ял»га озатабыз.

Эчлек өчен кирәк: эре угычтан уылган 300–400 гр сыр, бераз атланмай. Камырны кисәкләргә бүлеп, түгәрәкләп җәябез, эчлекне салып, бөрәбез һәм икенче ягына әйләндереп, өстеннән уклау белән 1–2 кат тәгәрәтеп, кызган табада ике яклап кыздырып алып, атланмай белән майлап, җылы чакта табынга бирәбез.

# ИРТӘН НӘРСӘ АШАМАСКА?




**Диетологлар әйтүенчә, тәүлекнең һәр сәгате өчен үз ризыгы бар. Кичке аш вакытында ашый торган ризыклар, мәсәлән, иртәнге сәгатьләрдә файдалы булмаска мөмкин. Сүз нинди ризыклар турында бара?**

1 **Җиләк-җимешләр.** Иртәнге яктан банан, әфлисун ашарга киңәш ителми. Беренчесендә магний күп күләмдә, ул организмда йөрәк-кан тамырлары авыруларын китереп чыгарырга мөмкин. Әфлисун исә ашказаны авырулары булган кешеләргә зыян гына китерәчәк.

2 **Йогырт.** Рекламага ышансаң, иртәнге ашка йогырттан да файдалырак ризык юктыр кебек тоела. Әмма бу – ялгыш фикер. Диетологлар әйтүенчә, йогыртны иртәнге аштан соң берничә сәгать үткәч яки йоклар алдыннан ашарга кирәк. Ашказаны өчен нәкъ менә шул вакытта аның файдасы булачак. Кибет йогырты урынына иртәнге ашка өйдә ясалганын кулланырга мөмкин.

3 **Тиз әзерләнә торган солы боткасы.** Андый боткаларның файдасы ташка үлчим генә. Аларда клетчатка бик аз була. 10 минутта әзер була дип кенә, вакытка алданып, кибет боткаларына өстенлек бирергә киңәш ителми. Иртә белән ботка пешерергә иренсәгез, аны кичтән банкага әзерләп куярга мөмкин. Җиләк-җимешләр, чикләвекләр дә өстәсәгез, аеруча тәмле һәм файдалы булыр.

4 **Кабартма.** Күпереп пешкән, өстенә шоколад ягылган, шикәр пудрасы сибелгән кабартмаларны, бик ашыйсы килсә дә, иртәнге ашка кулланмавың хәерлерәк. Май, шикәр һәм углеводлар көнне башлау өчен бик үк яхшы формула түгел. Кабартма урынына сырниклар пешерергә мөмкин. Аксым ягыннан каты пешкән йомырка да кабартмага алмаш була ала.

5 **Май белән ипи.** Моңа өстәп каһвә! Бер карасаң, тамакны туйдыра алырдай иртәнге аш, шулай бит? Әмма мондый иртәнге сый калория, аксым юклыгы, шикәрнең күплеге белән аерылып тора һәм организм өчен файдага түгел. Май урынына ипигә авокадо изеп сыларга була.

Белү зыян итмәс

## *Шешәдә дә үсә*



Яшел кыяклы суганны аш-суда еш кулланабыз. Әле бакча сезонына иртәрәк, әмма суганны тәрәзә төбендә үк үстерә башларга була инде.

Кирәк булыр: **пластик шешә (1,5–5 литрлы), паяльник (яки кайнар кадак), вак суган, дренаж, туфрак.**

Иң элек, шешә төбендә тишекләр ясыйбыз. Аннары төптән 5–6 см чигенеп, шахмат тәртибендә шешә биеклеге буенча суган утырту өчен тишекләр тишәбез. Аларның диаметры суганныкыннан бераз кимрәк булырга тиеш. Аннан соң шешәнең өске өлешен кисеп алабыз. Шешәне туфрак белән тишемнәрнең беренче рәтенә кадәр тутырабыз, тыгызлыйбыз. Әзер суганнарны салабыз (тишемнәрдән күренеп торсыннар), туфракны икенче рәт тишемнәргә кадәр тутырабыз, тыгызлыйбыз. Шешә тулганчы шулай итәбез, ахырдан су сибәбез.

Суганны кичтән суга салып калдырсагыз, яхшырак булыр.



Рәшит МИНҺАҖ

# ӘБИЛӘРГӘ НИ ҖИТМИ?



«Татар-информ»

**«Өйдә оныкларын тәрбияләп утырасы урында атна буе мәчет-мәдрәсә юлын таптыйлар». Кайбер зыялыларыбыз әбиләребез адресына шундыйрак дәгъва белдерә башлады. Икенче караганда, социаль челтәрләргә «чумып», сериалларга һушы китеп, намазга басу турында уйлап та карамаучылар да аз түгел. Алтын урталык кайда? «Иске таш» мәчет имамы Рамил хәзрәт Юныс белән шул сорауга җавап эзләдек.**

Бисмилләһир-рахманир-рәхим! Беренчедән, әбиләребезгә рәхмәтле булырга кирәк. Мирхәйдәр Фәйзинең 120 ел элек язылган «Галиябану» әсәрендә Бәдри хакында, кырык яшьлек карт, дип әйтелә. Ул вакытта, чынлап та, 40–45 яшьлек агайларның шактые җәй көне капка төбендә аягына киез итек, башына куян бүрек киеп, фани дөнья белән араны өзәргә вакыт җитеп киләдер, дип утырган. Хәзер, 120 елдан соң тормыш ничек үзгәрде, дөнья көтү нинди җиңеләйде. Хаҗга ярты көндә барып җитәбез, элек ел буе барганнар. Хәзер физик эш бик аз. Элек көзен, колхозның бәрәңгесен, чөгендерен, кишерен алып бетерми торып, авыл җирендә мәктәптә юньләп уку юк иде. Бүген кул эше азайды, авыр эш бетте. Сер түгел, физик хәрәкәтләнү кимегәч, төрле-төрле авырулар да барлыкка килә. Гомер озынлыгы да артты. Миңа соңгы вакытта, хәзрәт, 80, 85 яшьлегемне уздырып алыйк әле, дип мөрәҗәгать итүче апалар, әбиләр күбәйде. «Миңа бу әлләни кирәк тә түгел, әмма балалар бик тели, икенчедән, туганнарымның җыеласы килә, туганлыкны ныгыту өчен мөһим, шул ук вакытта табынга хәләл ризык куеп үткәрәсем килә, шуңа күрә сине чакырабыз», – диләр. Әле күптән түгел 83 яшьлек бер әби кафега, үз туган көненә машинасында килде, телефонында Инстаграмда лайклар куеп утырды. Заманнан калышмыйлар. Мин бер караганда бу гамәлләрен хуплыйм. Әгәр юбилейларын хәләл ризык куеп, туганлык мөнәсәбәтләрен ныгытып, вәгазь тыңлап үткәрсә, бер каршылыгым юк.

Шулай ук соңгы елларда шактый әби-абыстайларыбыз мәчетләргә юнәлде. Мин боларны да хуплыйм. Чөнки күбесенә элекке заманда дин белемен алырга туры килмәде. Динсезлек чорында эшләделәр, яшәделәр. Телевизордан сериаллар карап, гайбәт сөйләп утырганчы, алар гыйлем алу юлына басты. Әнә Пәйгамбәребез: «Бишектән алып ләхеткә кадәр белем алыгыз!» – дигән. Мөселман кеше үлгәнче гыйлем алырга тиеш. Мәчет-мәдрәсәгә килгәннәр икән, димәк, алар хәерле юлда! Кызганыч, мәчет-мәдрәсәләребездә сабак тыңлаучылар арасында ир-атларга караганда, хатын-кызлар, әбиләр саны күбрәк. Ни өчен Аллаһы Тәгалә җомга намазына ирләргә килүне мәҗбүри иткән? Ни өчен хатын-кызларга бу эш мәҗбүри түгел? Чөнки ир кеше, әти кеше, җомга намазында сөйләгән вәгазьләрне өйдәгеләргә җиткерергә тиеш. Ягъни гаилә әтидән ишетергә тиеш. Гаиләдә әти – тәрбияче. Әтидән ишетелгән сүзгә хатын да, балалар да колак сала. Ни кызганыч, ирләрнең моңа йә вакыты җитми, йә бу эшнең зарурлыгын аңлап бетерми. Әлбәттә, ирләр күбрәк йөрсә иде дип телик. Хатын-кыз гаиләне дә тартып бара, гыйлем дә ала. Менә шушы хатын-кызларның, мәчет-мәдрәсәдә гыйлем алганнан соң, өйдә әкрен-әкрен үгетләп, нәсыйхәтләп ирләрен дә намазлы, хаҗлы иткәннәре дә бик күп.

**:: Мәдрәсәдә гыйлем эстәгән абыстайларның оныкларына тәрбия-белем бирергә вакыты каламы соң?**

– Дини тәрбия бирү өчен әүвәл үзең белем алырга кирәк. «Хәзер дин белеме алам да кызыма да сөйлим, оныгыма да аңлатам», – дип уйлый ул. Гыйлемсез, динсез әбидән тәрбия алуга караганда, мәчет-мәдрәсәдә өч-биш ел укучы әбидән сабак тыңлавың күпкә хәерлерәк. Чөнки болар җир белән күк арасы кебек. Әби оныкны догага, Коръән укырга, Аллаһны яратырга өйрәтә. Дини гыйлем алмаган әби, билгеле, мондый гыйлемне бирә алмый. Шуңа күрә без әби-апаларның мәчеткә тартылуын тискәре күренеш дип карамыйбыз.

**:: Хәзрәт, шул ук вакытта өч еллык курсларда, кабат-кабат килеп, биш-ун ел укучы әбиләр дә бар.**

– Монда инде нәрсә әйтим?! Димәк, кемдер гыйлем алудан тәм тапкан. Ул шушы юлга баскан. Фатиры бар, телевизор карамый ул. Намаз укырмын, вәгазь ишетермен, белмәгәнемне белермен, дип килә. Бәлки оныклары да юктыр. Бәлки аралашмыйдыр. Театрга, концертларга йөрмәсә, гайбәт сатып утырулардан өстен булса, мәчеткә йөри. Без моның зыянын күрмибез. Билгеле, өй эшләрен калдырып, ирен карамыйча, оныкларын күрмичә, туганнары белән аралашмыйча, шәхси бурычын үтәмичә, гел мәчет юлында йөри икән, без моны хупламыйбыз. Хатын-кыз мәчеткә йөрергә тиешме дигән мәсьәләне хәтта Пәйгамбәребез алдында да күтәргәннәр. «Гыйлем алырга, сабакка дип барсалар, хатыннарыгызны мәчеткә йөрүдән тыймагыз. Дөрес, өйләре алар өчен хәерлерәк», – дип җавап биргән ул бу уңайдан. Гомумән, намаз уку өчен аларга мәчеткә йөрергә кирәкми. Өйдә намаз укысалар да, ирләре кебек, 27 савап алалар.

**:: Җомга көнне «Ярдәм» мәчетенең икенче катында шундый хәлгә юлыкканым бар. Бервакыт берничә абыстай безгә: «Хатын-кызларның намаз укый торган урыны бит бу», – дип дәгъва белдерде.**

– Без мәчетебездә ирләр күбәя икән, хатын-кызларны аска төшерәбез. Әгәр ирләр тагын да күбрәк килә икән, хатын-кызларга, җомга намазына килмисез, дип әйтәбез. Дөрес, безгә чит төбәкләрдә яшәгән хатын-кызлар да вәгазь тыңларга килә. Вәгазь үзенә күрә кешегә рухи азык та бирә. Шунсыз кеше бушый, күңелгә бозык уйлар керә башлый. Кем генә булмасын, мин мәчеткә килгән кешене гаепләү ягында түгел. Чөнки мәчеткә теләсә кем килә алмый. Мәчеткә килү өчен, беренчедән, Аллаһның рәхмәте, икенчедән, шайтанны җиңәргә ихтыяр көче кирәк. Әгәр мәчет әдәбен үтәп, тиешле гыйлем алып, тиешсез сүзләр сөйләмәсә, тавыш чыгармаса, аларга бернинди каршылыгыбыз юк. Киресенчә, аларның мәчеткә йөрүләрендә файда бар. Беренчедән, алар ярдәмчел. Сер түгел бит, саран кешеләребез – иң байлар, иң юмартлар – пенсиядәгеләр. Безнең илдә пенсиядәгеләрдән дә юмарт кеше юк. Ул коммуналь чыгымнарын түли, бик кирәкле нәрсәсен ала да, мәчеткә өлеш чыгармыйча калмый. Хәзрәтләрдән хәлләрне сорашып, улларына, оныкларына әйтеп мәчеткә ярдәм кулы суздыручылары да бар. Алар авыз ачу мәҗлесе, Коръән ашы да уздыра, аш уздырганда пешерергә, җыештырырга да булыша. Бүген, ни кызганыч, мәчеткә нигездә хатын-кызлар тормыш бирә. Коръәни-Кәримнең «Тәүбә» сүрәсендә Аллаһы Тәгалә: «Мәчеткә тормыш бирүчегә бик күркәм карыйм», – дип әйтә. Мәчетнең дивары, түбәсе, бүлмәләре бар. Әле тагын аның эчке рухи тормышы бар. Хәзер менә безнең «Иске таш» мәчеткә йөзләп апалар, абыстайлар, шул исәптән ирләр, яшьләр дә дәрескә йөри. Аллаһы Тәгалә шушы рәвешле мәчетнең гыйлем, вәгазь мәркәзе булуын тели. Алар шушы вазифаны үти.

**:: Бервакыт, бәхетле тормышның берничә нигезе бар, дип сөйләгән идегез. Шуларны кабат искә төшереп китик әле, хәзрәт.**

– Бәхетле тормышның алты нигезе бар. Аның беренче нигезе – иман, дин. Икенчесе – сәламәтлек. Өченчесе – ризык. Дүртенчесе – гаилә. Бишенчесе – эш. Алтынчысы – җәмгыятьтә тоткан урының. Ислам дине безгә шушы нигезләрнең һәрберсенә бертөрле игътибар бирергә куша. Шуларның берәрсе онытыла икән, өйдә гауга чыга башлый. Аллаһтан хәбәр килде дигән сүз бу. Эш белән генә мавыкмаска, балалар белән чаңгы шуып та кайтырга кирәк икән. Без еш кына акча, ризык кирәк дип, сәламәтлекне кайгыртырга онытабыз. Әнә кайбер мөселман егетләребез иртәнге намазга скандинав таяклары тотып килә. Җәяү килә, сәламәтлеген кайгырта. Тормышта бездән алда барган, уңышка ирешкән кешеләргә карагыз әле: шушы нигезләрнең барысына да игътибар бирергә тырышалар. Ул баласы белән дә уйнап алган, әти-әнисенең дә хәлен белешеп чыккан. Эшендә дә яхшы. Футбол уйнарга да вакыт тапкан. Һәрберсенә бертөрле игътибар бирсәк, тормышыбыз дөрес бара.
Рухи якка зур игътибар биреп, мәчеткә еш йөрүче, озаклап утыручы ирләрне беләм. Гаиләсе ничек яшәргә дип аптырый, мохтаҗлык кичерә. Чөнки бу ир, әти кеше көнтөн мәчеттә. Алай да булмый. Гомәр ибне Хаттаб хәлифә булган вакытта иртәнге намаздан, Кояш чыкканнан соң кем дә кем мәчеттә Коръән укып утырса, син ике аяклы, ике күзле, дип аны куып чыгарган. Кояш чыкканнан соң гыйбадәт эшкә күчәргә тиеш. Төне буе Коръән укыгансыз икән, көндез шуның гамәлен кылыгыз! Хәтта безнең «Җомга» сүрәсендә дә Аллаһы Тәгалә: «Әй иман китергән бәндәләр! Җомгага азан тавышы ишетелсә, сәүдәгезне калдырыгыз да намазга ашыгыгыз. Намаз бетүгә, тагын эшкә китегез», – ди. Ягъни эшләргә тиешбез. Кайберәүләр җомганы ял көне дигән була. Аңлашыладыр: намазны укып бетерүгә, тагын эшкә ашыгырга кирәк. Ягъни мөселман кешесенең тормышы: гыйбадәт – эш – гыйбадәт – эш. Билгеле, арада ашы, ялы да бар. Менә шулай гел алмашынып тора.
Мәчеткә йөрүче хатын-кызларга да әйтәм: гел гыйбадәттә яки сабак тыңлап утырып, хәләл җефетегез назыгызны, кайгыртуыгызны күрмәсә, өйгә кайткач, хөрмәтләп каршы алучы булмас. Алган белемеңне дөрес итеп файдаланмау бу. Хәзерге вакытта байтак кына әти-әни кызларын бәйсез, мөстәкыйль итеп тәрбияләргә тырыша. Вузда укыганда ук фатир алып бирергә, аннан яхшы гына эшкә урнаштырырга тырыша. Әле машина да алып бирсәләр, иренә ул хезмәт күрсәтүче итеп кенә карамасмы?! Шул сәбәпле хәзер күп кенә ирләр гаиләдә икенче урында калып бара. Ирләренең беренче урында булырга тиешлеген таный алмаган, мәчеткә йөреп тә шул вазифаны үтәмәгән хатын-кыз, әлбәттә, үзенең хакын үтәми торган кеше булып чыга.

**:: Хәзер укучы балалар, яшьләр генә түгел, кайбер әбиләр дә озаклап социаль челтәрләрдә утыра.**

– Әгәр эшлекле тәкъдимнәр, вәгазь куясың, изгелеккә чакырасың икән, интернет – яхшы нәрсә. Сәүдәгәрләр аны үзләрендәге малны рекламалау, сату өчен файдаланырга тырыша. Бу – икенче әйбер. Рәсемнәреңне, пешергән ризыкларыңны, сәфәрләреңне интернетка куеп мактану – мәгънәсезлек ул. Шушылай башкалар каршында масаеп, тәкәбберләнеп, бүтәннәрне көнчелеккә, хөсетлеккә этәрәләр. Нәтиҗәдә күз тидерәләр, сихергә тап булалар, тормышларының бәрәкәте китә. Социаль челтәр – бик куәтле чара, әмма аны дөрес кулланырга кирәк. Тел дә бик куәтле нәрсә: яман сүз кеше үтерә, дип юкка гына әйтмиләр. Ахирәткә баргач, менә шушы кесә телефоннары өчен әле җавап бирәчәкбез. Нинди генә чор, технология булмасын, динне дөрес аңлап торкан кеше бу дөньяда адашмаячак.

## МӨФТИ СҮЗЕ

### Күңелебез тыныч булсын

Аллаһның Илчесе әйтте: «Аллаһтан курык, кайда гына булсаң да, начар гамәл артыннан, үзе белән начарлыкны сөртә торган изгелекне кыл, кешеләр белән мөгамәләдә әдәпле бул».

Күңелендә бөртек кадәр генә булса да изгелек булган кеше, ялгыш берәр начарлык эшләгәннән соң үзен гаепле хис итә башларга мөмкин. Нииндидер кыенсызлык, шомлану сизелгән очракта, һич булмаса сәдакә биреп, Аллаһтан күңелләребезгә тынычлык сорыйк.

### Яман чирдән саклансак иде

Кешеләр арасында бик күп рухи авырулар бар: яманлык, көнләшү, ялган, бер-берсенә нәфрәт һәм башкалар. Үзебезгә теләгәннәрен кардәшләребезгә теләмәсәк, шул калеб авыруларыннан котылып булмас.

Шулар арасындагы иң куркыныч авыруларның берсе – көнчелек. Бу сыйфат аркасында кеше үзенә һәм башкаларга зыян китерә. Бу сыйфат башка гөнаһларга юл ача һәм иң әүвәл якыннардан, дуслардан, күршеләрдән башланып китә. Дөреслектә, көнчелек хисе тәкъдир һәм Аллаһның исемнәрен, сыйфатларын начар аңлаудан килеп чыга.

Бу яман чирдән саклансак иде.

Камил хәзрәт СӘМИГУЛЛИН